МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2015 № 487

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 14 августында теркәлде, № 2845

Татарстан Республикасы бюджеты
яки җирле бюджетлар акчалары хисабына
төп белем бирү программалары буенча
һөнәри белем бирү оешмаларында
һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында
белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән
мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар,
ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар
исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын
һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын
тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме,
йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга
бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау хакында

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. “Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге” дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р.Фәйзуллинга: Регламент нигезләмәләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 21.07.2015 ел, № 487 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар булып Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында көндезге уку формасында белем алучы ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, уку дәверендә әти-әнисенең икесен дә яки берләнбер булганын югалткан студентлар, шул исәптән 23 һәм аннан артыграк яшькә җиткәннәре (Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар исәбендәгеләр, әгәр федераль закон яки Россия Федерациясенең халыкара

килешүе белән башкача билгеләнмәгән булса) тора.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча укып, мәгариф эшчәнлеге алып баручы оешмаларны тәмамлаганнарга (Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча көндезге уку формасында укуларын дәвам иттерүче затлардан гайре) күрсәтелә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (законнарда күздә тотылган очракларда) яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге" дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы бүлеге (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан, һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы урнашкан җирдә яки дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында күрсәтелә.

1.4.1. Үзәк бүлекләренең урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

Үзәк бүлегенең эш графигы: "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге" дәүләт казна учреждениесенең эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән эш сәгатьләрендә шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша;

2) "Интернет" челтәре аша:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында: http://www.mtsz.tatarstan.ru;

3) Үзәк бүлегенә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Регламентның 1.1, 1.4.1, 1.5, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы,

2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

“Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 17.12.2004 ел, № 542 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2005, № 1-2, 0018 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашуның “Торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында” 22.01.2005 ел, № 20 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – № 20 ТР МК карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2005, № 5, 0156 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата (27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты). Гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтүгә стандарт таләбе атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары хисабына төп белем бирү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлап чыкканда, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү пособие билгеләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган пособие ) | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге" дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы бүлеге | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 1.3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6.9 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта кабул ителә. | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6.9 п. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында бу Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза;<br>әти-әнисенең икесен дә яки бердәнбер булганын югалтуны раслаучы документлар – уку дәверендә әти-әнисенең икесен дә яки бердәнбер булганын югалткан студентлар өчен;<br>югары белем бирү мәгариф оешмасыннан баланың, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затның укуын раслаучы белешмә (мәгариф оешмасын тәмамлап чыгу көнен күрсәтеп).<br>Дәүләт хезмәте алучылар вәкаләт биргән затлар һәм законлы вәкилләр, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләрен тапшыра.<br>Документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.<br>Гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче паспортын (аны алмаштыручы документын) һәм банкта ачылган лицевой счет реквизитларын күрсәтә.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, гаризага кушып бирелә торган документлар күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланган булырга тиеш. | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6.6, 6.8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар кергән документлар алына:<br>опека (химаячелек) билгеләү турында – ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар өчен (җирле үзидарә органнарыннан);<br>баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуын раслаучы (кергән һәм укып бетергән датасын күрсәтеп) (һөнәри белем бирү оешмаларыннан).<br>Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлардан торган документлар тапшырырга хокуклы, шул исәптән, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматларны эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый. | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6.7 п.; № 20 ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 6 п. |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.<br>2. Гариза бирүченең Үзәкнең һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы урнашмаган яки дәүләт хезмәте алучы яшәмәгән урындагы бүлегенә мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигез булып, гариза һәм документлар күчермәләрен № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру тора. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы – бу Регламентның 2.5 пункты белән күздә тотылган документларны биргәнче, әмма документларның төп нөсхәләрен яисә аларның нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма) тарафыннан расланган күчермәләрен күрсәтү зарурлыгы турында хәбәр бирелгән көннән башлап 10 көннән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр:<br>бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау;<br>документлар белән бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>гариза һәм документлар күчермәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган электрон документлар рәвешендә җибәргән очракта, документларның кәгазьдәге төп нөсхәләрен яисә аларның нотариус яки документның төп | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6.10, 6.12 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | нөсхәсен биргән орган (оешма) тарафыннан расланган күчермәләрен күрсәтү зарурлыгы турында хәбәр бирелгән көннән башлап 10 көн эчендә аларны күрсәтмәү;<br>электрон рәвештә җибәрелгән документларының гариза бирүче тапшырган төп нөсхәләргә туры килмәве;<br>баланы, студентны һөнәри белем бирү оешмасыннан яки югары белем бирү мәгариф оешмасыннан чыгару;<br>һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлап чыкканда, бер тапкыр бирелә торган пособиене элегрәк алган булу;<br>баланың, студентның үлеме. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең | Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең чиратта көтү вакыты 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | № 601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| максималь срогы | | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы | Гариза һәм кирәкле барлык документлар кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырылган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән һәм:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>бүлек биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге; | № 880 ТР МК карарының 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | гариза һәм документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинеты аша алу мөмкинлеге (гариза һәм документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген гамәлгә ашырганнан соң).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан бу Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүчеләрнең Үзәк бүлеге белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:<br>1) әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, турыдан-туры аралашу таләп ителми;<br>2) әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль | |

| | | |
|---|---|---|
| | закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бердән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүче белән Үзәк бүлеге белгеченең бер тапкыр аралашуы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Үзәкнең бүлегенә № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.<br>Гариза һәм документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru.) аша бирүнең техник мөмкинлеге булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар күчермәләре электрон имза белән № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) очракта, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү | № 542 ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 10.1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны бу Регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән срокларда Үзәк бүлегендә күрсәткәч кабул ителә. | |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 4 нче кушымтада бирелә.

3.1.3. Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 5 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

3.2.1. Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Үзәк бүлегенә шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлеге белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гражданин шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә, документларны почта аша җибәргәндә дәүләт хезмәте күрсәтү

3.3.1. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

Гариза бирүче Үзәк бүлегенә бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында гариза һәм, аңа кушып, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә, документлар бирә.

Гариза һәм документларның нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланган күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон документлар рәвешендәге гариза һәм, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон чараларны кулланып тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларын кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра, гариза почта аша җибәрелгән булса, гаризаны теркәү көне һәм бирелгән керү номеры турында хәбәрнамә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булган очракта, Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булу турында хәбәр итә һәм, баш тартуның ачыкланган нигезләрен язмача аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза һәм документлар почта аша алынган булса, Үзәк бүлеге белгече, баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны почта аша кире җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы булдыру, документларны кабул итү турындагы расписка, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә, гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.2. Мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү

3.3.2.1. Үзәк бүлеге белгече һөнәри белем бирү оешмаларыннан, электрон рәвештә, баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуын раслаучы (укырга кергән һәм укуны тәмамлаган датаны күрсәтеп) мәгълүматлар булган документ ала.

3.3.2.2. Үзәк бүлегендә бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Үзәк бүлеге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы

ярдәмендә, түбәндәге мәгълүматлар бирүне сорап, рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

опека (химаячелек) билгеләү турында – ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар өчен – җирле үзидарә органнарына;

баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуын раслаучы (укырга кергән һәм укуны тәмамлаган датаны күрсәтеп).

Бу Регламентның 3.3.2.1, 3.3.2.2 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында мөрәҗәгатьләр, алынган мәгълүматлар.

3.3.3. Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.3.3.1. Үзәк бүлеге белгече бу Регламентның 3.3.2.1, 3.3.2.2 пунктларында күрсәтелгән алынган мәгълүматлар һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә, түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле яисә алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында, бу Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча, карар проектын рәсмиләштерә;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән моменттан ике эш көне эчендә, ләкин моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алты көннән дә соңга калмыйча үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты.

3.3.3.2. Документларны карап тикшергәннән соң, Үзәк бүлеге җитәкчесе бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар.

3.3.4. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече:

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карарны, гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе белән (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта белән) гариза бирүчегә хәбәр итә;

гариза бирүченең “личное дело”сын рәсмиләштерә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү, гариза бирүченең рәсмиләштерелгән “личное дело”сы.

3.4. Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.4.1. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

Гариза бирүче Үзәк бүлегенә Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны электрон документлар (документлар күчермәләре) рәвешендә тапшыра.

Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гариза бирүчегә Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинеты аша документларның кабул ителүе һәм гаризаның теркәлүе турында хәбәр итә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына хәбәр җибәрү юлы белән, документларны кабул итүдән һәм гаризаны һәм документларны теркәүдән баш тартуга нигезләр булу турында хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналына язылган теркәү язуы, документларны кабул итүдән баш тарту, гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.4.2. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.2.1. Үзәк бүлеге белгече һөнәри белем бирү оешмаларыннан, электрон рәвештә, баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуы турында (укырга кергән һәм укуны тәмамлаган датаны күрсәтеп) мәгълүматлар булган документ ала.

3.4.2.2. Үзәк бүлегендә бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Үзәк бүлеге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, түбәндәге мәгълүматларны бирүне сорап, электрон рәвештә мөрәҗәгатьләр җибәрә:

опека (химаячелек) билгеләү турында – ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар өчен – җирле үзидарә органнарына;

баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуын раслаучы (укырга кергән һәм укуны тәмамлаган датасын күрсәтеп).

Бу Регламентның 3.4.2.1 пункты һәм шушы пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә алынган мәгълүматлар.

3.4.3. Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү.

3.4.3.1. Үзәк бүлеге белгече, бу Регламентның 3.4.2.1, 3.4.2.2 пунктларында күрсәтелгән алынган мәгълүматлар нигезендә, түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әгәр гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә тапшырган гариза һәм документлар № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган булса, гариза бирүчегә Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына хәбәр җибәрү юлы белән бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге хәбәрнамә җибәрелгән көннән башлап ун көн эчендә тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән моменттан башлап бер эш көне эчендә, ләкин моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан алты эш көненнән дә соңга калмыйча үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.4.3.2. Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон формада бу Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгәнчә рәсмиләштерә;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон формада Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куярга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көнендә башкарыла.

Үзәк бүлегенә Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бу Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән срокка туктатып торыла. Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты гариза бирүче бу Регламентның 2.5 пунктында әйтелгән документларны күрсәткән көнне рәсмиләштерелә, әгәр алар бу Регламентның 2.5 пунктында әйтелгән документларны күрсәтү зарурлыгы турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срок тәмамланганга кадәр күрсәтелсә. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру зарурлыгы турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срок узса, бер тапкыр бирелә торган пособие

билгеләүдән баш тарту турындагы карар проекты рәсмиләштерелә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән электрон рәвештәге карар проекты.

3.4.3.3. Документларны карап тикшергәннән соң, Үзәк бүлеге җитәкчесе бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны электрон имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан электрон имза белән имзаланган карар.

3.4.4. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлеге белгече:

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан электрон имза белән имзаланган карарны гариза бирүченең Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына җибәрә;

гариза бирүченең “личное дело”сын рәсмиләштерә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан электрон имза белән имзаланган, гариза бирүченең Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына җибәрелгән карар, гариза бирүченең рәсмиләштерелгән “личное дело”сы.

3.5. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

3.6. Техник хаталарны төзәтү.

Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында элегрәк бирелгән карарда җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хаталар) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ теркәлгән гариза (бу Регламентка 6 нчы кушымта) нигезендә башкарыла.

3.6.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турындагы кабул ителгән, теркәлгән гариза, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән карар проекты.

3.6.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура карар проекты имза куюга җибәрелгән моменттан бер көн эчендә үтәлә.

